**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2021 Балык Бистәсе штп. № 101пг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында остазлык оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 7 октябрендәге “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә остазлык турындагы нигезләмәне раслау хакында” 1296 номерлы карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 октябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында остазлык оештыру турында” 978 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 7 октябрендәге “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә остазлык турындагы нигезләмәне раслау хакында” 1296 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә остазлык турында Нигезләмәгә (алга таба – остазлык турында Нигезләмә) ярашлы рәвештә остазлыкны гамәлгә ашыру буенча эшне оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәттә остазлык оештырганда остазлык турындагы Нигезләмәгә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

остазларны билгеләүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы иң абруйлы, тәҗрибәле һәм нәтиҗәле муниципаль хезмәткәрләр (алга таба – хезмәткәрләр) арасыннан гамәлгә ашырырга;

хезмәткәрнең остаз сыйфатында эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген аңа аеруча

мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр түләгәндә исәпкә алырга;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда иң яхшы остазлар турында мәгълүмат урнаштыру эшен оештырырга.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында остазлык һәм муниципаль хезмәткәрләрнең җайлашу системасы турында” 2015 елның 23 гыйнварындагы 19пг номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Документ КонсультантПлюс тарафыннан тәкъдим ителде

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ХӨКҮМӘТЕ**

**КАРАР**
**2019 елның 7 октябре, № 1296**

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАНЛЫК ХЕЗМӘТЕНДӘ ОСТАЗЛЫК ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘНЕ РАСЛАУ ХАКЫНДА

"Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең һөнәри үсеше турында" Россия Федерациясе Президентының 2019 елның 21 февралендәге 68 номерлы Указының 4 пунктындагы "в" пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте карар бирә:

1. Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтендә остазлык турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарда каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру күрсәтелгән органнар хезмәткәрләренең билгеләнгән чик саны һәм федераль бюджетта билгеләнгән функцияләр өлкәсендә җитәкчелек итүгә һәм идарә итүгә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә федераль дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе
Хөкүмәте Рәисе
Д.МЕДВЕДЕВ

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең
2019 елның 7 октябрендәге
1296 номерлы карары белән
расланды

## Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтендә остазлык турында Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтендә остазлыкны гамәлгә ашыру тәртибен (алга таба тиңдәшле рәвештә – гражданлык хезмәте, остазлык) һәм, аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүне исәпкә алып, Россия Федерациясенең остазлыкны (алга таба – остазлар) гамәлгә ашыручы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) кызыксындыру шартларын билгели.

2. Гражданлык хезмәтендә остазлык, гражданлык хезмәткәрләренең һөнәри үсешенә ярдәм итү максатыннан, югары һөнәри дәрәҗәдә хезмәт эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр формалаштыруга һәм вазыйфаи бурычларны үтәүгә намуслы мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән аерым бер өлкәдә шактый эш тәҗрибәсе булган затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Остазлыкның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

а) остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең үз алдында торган дәүләт органы эшчәнлегенең юнәлешләре һәм максатлары турында мәгълүматын арттыру, шулай ук гражданлык хезмәтенә беренче тапкыр килгән гражданлык хезмәткәрен яисә әлеге дәүләт

органына беренче тапкыр кергән гражданлык хезмәте стажы булган гражданлык хезмәткәренең күнегү-җайлашу процессын тизләтү;

б) остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең үзенә йөкләнгән вазыйфаи йөкләмәләрне мөстәкыйль, сыйфатлы һәм үзвакытында үти белүен үстерү һәм аларны тиешенчә үтәү өчен кирәкле һөнәри дәрәҗәсенә ярдәм итү;

в) остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәвенә, нәтиҗәле һәм озак сроклы һөнәри хезмәт эшчәнлегенә мотивациясен (теләк-ниятен) арттыру.

4. Остазлык яллаучы вәкиленең карары буенча гамәлгә ашырыла (дәүләт органы җитәкчесе, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасын яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасын биләүче зат, яки күрсәтелгән җитәкченең яисә яллаучының Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты исеменнән вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы затның вәкиле).

5. Яллаучы вәкиле остазлыкны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра.

6. Дәүләт органында остазлыкны оештыруны, шул исәптән гражданлык хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдаланып, дәүләт органының кадрлар хезмәте башкара.

7. Остазлык, кагыйдә буларак, дәүләт органына беренче тапкыр гражданлык хезмәтенә килгән гражданлык хезмәткәренә яки әлеге дәүләт органына беренче тапкыр килгән гражданлык хезмәте стажы булган гражданлык хезмәткәренә карата гамәлгә ашырыла.

8. Остазлыкны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдим яллаучы вәкиленә аңа карата остазлыкны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган зат тарафыннан гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү күздә тотылган дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан җибәрелә (алга таба – турыдан-туры җитәкче). Әлеге тәкъдим гражданлык хезмәткәренең остаз итеп билгеләнә торган остазлык срогы һәм ризалыгы турындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

9. Остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе, остазның озак вакыт дәвамында хезмәткә яраксызлыгы яисә аның озак вакытлы хезмәт командировкасы очрагында, шулай ук остазлыкны тормышка ашыруга комачаулаучы башка хәлләр барлыкка килү очрагында әлеге хәлләр барлыкка килгән вакыттан алып бер эш көне эчендә яллаучы вәкиленә башка остазны билгеләү турында карар кабул итү өчен тәкъдимнәр җибәрә. Шул ук вакытта остазлык вакыты үзгәрми.

10. Остазлык, үзенә карата остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәре шул ук яисә башка дәүләт органында гражданлык хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләнгән очракта яисә гражданлык хезмәтеннән азат ителгән очракта, билгеләнгән срок тәмамланганчыга кадәр туктатыла.

11. Остаз иң абруйлы, тәҗрибәле һәм нәтиҗәле гражданлык хезмәткәрләре арасыннан билгеләнә. Остазның дисциплинар җәзасы яки коррупцион хокук бозу өчен җәзасы булырга тиеш түгел, шулай ук аңа карата хезмәт тикшерүе үткәрелергә тиеш түгел.

12. Остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе остаз була алмый.

13. Остаз бер үк вакытта 2 дән артык булмаган гражданлык хезмәткәренә карата остазлык күрсәтә ала.

14. Остазлык функцияләре остаз булып торган гражданлык хезмәткәре тарафыннан аның үз вазыйфаи бурычларын үтәве белән бергә гамәлгә ашырыла.

15. Остаз функциясенә түбәндәгеләр керә:

а) гражданлык хезмәткәренә гражданлык хезмәтен үтү шартлары белән таныштыруда булышлык күрсәтү;

б) гражданлык хезмәткәренә үзенең вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр тапшыру;

в) гражданлык хезмәткәренә һөнәри хезмәт эшчәнлеген башкарганда җибәрелгән хаталарны ачыклау һәм аларны бетерүдә ярдәм итү;

г) тупланган тәҗрибәне, һөнәри осталыкны тапшыру, вазыйфаи бурычларны башкаруның иң рациональ ысулларын күрсәтү һәм аңлату;

д) гражданлык хезмәткәренә һөнәри киңәш сорап мөрәҗәгать иткәндә консультатив-методик ярдәм күрсәтү.

16. Остазның түбәндәгеләргә хокукы бар:

а) остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләре буенча аның турыдан-туры җитәкчесе белән фикер алышуда катнашу;

б) гражданлык хезмәткәренә вазыйфаи бурычларын үтәү буенча практик күнекмәләр булдыруга ярдәм итә торган тәкъдим-киңәшләр бирү;

в) остазлык буенча чараларның индивидуаль планын эшләү;

г) гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үзвакытында үтәвен контрольдә тоту.

17. Остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәреннән хезмәт контрактында һәм вазыйфаи регламентында билгеләнмәгән вазыйфаи бурычларын үтәүне әлеге гражданлык хезмәткәреннән таләп итү тыела.

18. Остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәре вазыйфаларына түбәндәгеләр керә:

а) остазның киңәш-тәкъдимнәрен исәпкә алып, турыдан-туры җитәкче биремнәрен мөстәкыйль үтәү;

б) куелган бурычларны гамәли хәл итүгә өйрәтү буенча остаз биргән тәҗрибәне үзләштерү;

в) остазның киңәш-тәкъдимнәрен исәпкә алу, остазлык буенча чараларның индивидуаль планын үтәү (булган сурәттә).

19. Остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәре түбәндәгеләргә хокуклы:

а) зарурлык булганда үз вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәү өчен остазга һөнәри киңәш сорап мөрәҗәгать итәргә;

б) турыдан-туры җитәкче һәм остаз белән остазлык белән бәйле мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашу;

в) турыдан-туры җитәкчегә остазны алыштыру турында нигезләнгән гариза (юллау) бирергә.

20. Остаз остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесенә остазлык срогы тәмамланганнан соң 2 эш көненнән дә соңга калмыйча кушымтада бирелгән форма буенча остазлык нәтиҗәләре турында бәяләмә бирә (фикерен белдерә).

21. Остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе остазлыкны гамәлгә ашыруга йомгак ясау максатларында мондый гражданлык хезмәткәре белән индивидуаль әңгәмә уздыра.

22. Остазлык гамәлгә ашырыла торган гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе остаз эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм гражданлык хезмәткәренең һөнәри эшчәнлеге нигезендә остазлык эшчәнлеге нәтиҗәсенә бәя бирә. Бәяләү түбәндәгеләрне исәпкә алып үткәрелә:

а) остазлык гамәлгә ашырылган гражданлык хезмәткәренә аның тарафыннан һөнәри белемнәрне, күнекмәләрне һәм осталыкларны уңышлы үзләштерүдә, аның һөнәри үсешендә ярдәм итү;

б) остазлык гамәлгә ашырылган гражданлык хезмәткәренә аның тарафыннан һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсендә белгечлек, юнәлеш буенча эш тәҗрибәсе алуда, анда гамәли белемнәр һәм күнекмәләр булдыру буенча булышлык итү;

в) остазлык гамәлгә ашырылган граждан хезмәткәренә эш формаларын һәм ысулларын камилләштерүдә даими һәм нәтиҗәле ярдәм күрсәтү;

г) остазлык гамәлгә ашырылган граждан хезмәткәрендә аның вазыйфаи бурычларын үтәвенә намуслы мөнәсәбәт тәрбияләү буенча нәтиҗәле эш алып бару.

23. Остаз тарафыннан әзерләнгән һәм кул куелган остазлык нәтиҗәләре турында бәяләмә (фикер), аңа карата остазлык гамәлгә ашырылган гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе танышканнан соң, остазлык срогы тәмамланганнан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча дәүләт органының кадрлар хезмәтенә җибәрелә.

24. Гражданлык хезмәткәренең остаз сыйфатында эшчәнлегенең нәтиҗәләрлеге яллаучы вәкиле карары буенча аңа аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия биргәндә исәпкә алына. Күрсәтелгән премияне остазларга түләү тәртибе “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” Федераль законның 50 маддәсендәге 5 өлешенең 4 пункты нигезендә яллаучы вәкиле тарафыннан тәгаенләнә.

25. Гражданлык хезмәткәренең остаз буларак эшчәнлеге гражданлык хезмәткәрен “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” Федераль законның 55 маддәсе нигезендә намуслы һәм нәтиҗәле гражданлык хезмәте өчен кызыксындыруга (хуплауга) яки бүләкләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл иткәндә исәпкә алына.

26. Дәүләт органы гражданлык хезмәткәрләрен "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында" Федераль законның 55 маддәсендәге 1 өлешенең 3 пункты нигезендә остазлыкны нәтиҗәле һәм озак вакыт гамәлгә ашырган өчен бүләкләү максатында ведомствоның аерымлык билгесен булдырып гамәлгә куярга хокуклы.

Россия Федерациясе
дәүләт гражданлык хезмәтендә
остазлык турындагы Нигезләмәгә
кушымта

(форма)

Остазлык нәтиҗәләре турында
БӘЯЛӘМӘ

1. Остазның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм биләгәнвазыйфасы: ____________________________________________________________
____________________________________________________________

2. Остазлык гамәлгә ашырылган Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәткәренең (алга таба - гражданлык хезмәткәре) Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) һәм биләгән вазыйфасы:
____________________________________________________________
____________________________________________________________

3. Остазлык чоры: 20__ елның ___________алып 20__елның ____________кадәр.

4. Остазлык нәтиҗәләре турында мәгълүмат:

а) гражданлык хезмәткәре һөнәри хезмәт эшчәнлегенең түбәндәге төп мәсьәләләрен өйрәнде:
____________________________________________________________
____________________________________________________________;

б) гражданлык хезмәткәре остазның тәкъдим-киңәшләре буенча түбәндәге төп биремнәрне үтәде:
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________;

в) гражданлык хезмәткәренә вазыйфаи бурычларны башкарганда түбәндәге җитешсезлекләрне бетерергә кирәк (зарурлык булганда тутырыла)____________________________________________________________
____________________________________________________________;

г) гражданлык хезмәткәренә өстәмә рәвештә түбәндәге мәсьәләләрне өйрәнергәкирәк:
____________________________________________________________
____________________________________________________________.

5. Граждан хезмәткәренең һөнәри потенциалын билгеләү һәм аның һөнәри үсешебуенча тәкъдимнәр____________________________________________________________
____________________________________________________________.

6. Остазлык гамәлгә ашырылган гражданлык хезмәткәре турында өстәмә мәгълүмат (зарурлык булганда тутырыла)____________________________________________________________
____________________________________________________________.

| | |
| --- | --- |
| Остазлык гамәлгә ашырылган гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесенең танышканлыгы турында тамга, остазның нәтиҗәләре белән | Остаз<br><br>(вазыйфасы) |
| ___________/_______________________<br>(имза) (имзаның расшифровкасы) | ___________/_______________________<br>(имза) (имзаның расшифровкасы) |
| "__" ____________________ 20__ ел | "__" ____________________ 20__ ел |

____________________________________________________________